ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел 18 октябрь с. Старое Дрожжаное № 120

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агач, куаклар кисүгә, кронлау, утыртуга һәм газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 9 августындагы 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агач, куаклар кисүгә, кронлау, утыртуга һәм газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 9 августындагы 76 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында "агачлар, куакларның торышы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында. «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. 2.6.1 пунктының 6,11 пунктчаларында. «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга.;

1.6. 2.6.3.пунктында. "Башкарма комитетның структур бүлекчәсе" сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга.;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында “гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, аеруча кирәк булган (авария хәлендәге агачларны) хәлдә булуы турында " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында. "(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки яшел үсентеләрне сүтүгә бәйле очраклардан тыш( агачның, зыян килгән агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында. 2 нче кушымтада " сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында “шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яисә яшел үсентеләрне сүтү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен)” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында. «; мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә һәрхәлдә яшел үсентеләрне сүтү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентның 2 нче кушымтасында " Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чупрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе: В.М. Салахутдинова